**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча республика ведомствоара комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча республика ведомствоара комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 5 апрелендәге ПУ-203 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 6 июлендәге ПУ-429 номерлы, 2011 елның 7 февралендәге ПУ-47 номерлы, 2012 елның 14 августындагы ПУ-652 номерлы, 2013 елның 25 сентябрендәге ПУ-930 номерлы, 2014 елның 25 гыйнварындагы ПУ-45 номерлы, 2015 елның 7 февралендәге ПУ-104 номерлы, 2016 елның 23 гыйнварындагы ПУ-23 номерлы, 2016 елның 21 мартындагы ПУ-267 номерлы, 2017 елның 20 гыйнварындагы ПУ-38 номерлы, 2017 елның 10 июнендәге ПУ-496 номерлы, 2017 елның 26 октябрендәге ПУ-975 номерлы, 2019 елның 6 маендагы ПУ-262 номерлы һәм 2020 елның 30 ноябрендәге ПУ-786 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча республика ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан М.М. Әхмәтовны чыгарырга;

б) Комиссия составына, аны Комиссия секретаре итеп раслап, Галләмов Айрат Азат улын – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының торак-коммуналь хуҗалык идарәсе башлыгын кертергә;

в) Комиссия әгъзасы М.В. Трофимованың фамилиясен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Прокофьева».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИИ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2022 ел, 25 ноябрь
№ ПУ-815